



# ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

***НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА ТАТАРСТАНА***

# NATIONAL LIBRARY OF TATARSTAN









Архитектураның һәм сынлы сәнгатьнең чын могҗизасы булган бу гаҗәеп бинага Татарстан җирендә һәм башка ил-дәүләтләрдә яшәүче халыкларның гаять бай рухи хәзинәсе тупланган.

Монда килгән һәрбер кеше, әйтерсең лә, акыл һәм гүзәллек чишмәсеннән авыз итә.

Әмма, авыз иткән саен, аның гыйлемгә һәм матурлыкка булган ихтыяҗы һич кимеми, киресенчә, күңел сусавы көчәя генә бара.

Татарстан Милли китапханәсе дип аталган акыл чишмәсенең изге суы беркайчан да кипмәс, аннан рухи байлык алырга теләүчеләр саны көннән-көн ишәя барыр дип ышанам.

Фәрит МӨХӘММӘТШИН,
Татарстан Республикасы
премьер-министры

В этом прекрасном здании, являющимся подлинным шедевром архитектуры и изобразительного искусства, собрано богатейшее духовное наследие народов, проживающих на земле Татарстана, а также — великие литературные памятники общечеловеческой культуры.

Каждый, кто входит сюда, как бы делает живительный глоток из глубочайшей чаши мудрости и красоты, очищает свою душу и помыслы, ясно осознает, что жажда познания неутолима и вечна.

Убежден, что сокровищница знаний, имя которой Национальная библиотека Татарстана, со временем не только не оскудеет, но и пополнится и засверкает новыми бесценными творениями, а желающих овладеть ее богатствами с каждым годом будет становиться все больше.

Фарид МУХАМЕТШИН,
премьер-министр
Республики Татарстан

In this beautiful building, that is the real masterpiece of architecture and art, we can see the richest spiritual heritage of the people of Tatarstan together with great memorials common to all mankind culture.

Everybody, who enters here, clings close to the deepest cup of wisdom and beauty, cleans his soul and thoughts, and comprehends, that the thirst for knowledge is relentless and eternal.

I believe, that this tresure-house of knowledge, the name of which is the National Library of Tatarstan, won't grow scarce for years, it will begin to sparkle with new priceless works, and for all comers the desire for receiving communion to all its spiritual wealth will increase.

Pharit MUKHAMETSHIN,
Prime-minister of the
Republic of Tatarstan

**Татарстан Республикасының Милли китапханәсе** татар халкы мәдәниятенең үзәк һәм бай мирасханәсе булып тора. Ул — дөньяда татар китабын һәм республика тормышына, халык язмышына кагылышлы әдәбиятны туплау, саклау, тарату белән шөгыльләнүче берләнбер китапханә. Аның хәзинәсендә 3 миллионнан артык төрледән-төрле китаплар һәм документлар, шул исәптән 78 мең татар һәм 80 меңнән күбрәк Гареп һәм Шәрекъ халыклары телләрендәге басма чыганаклар саклана. 14 мең нөсхәдән артык кулъязма һәм сирәк очрый торган басма китаплар — китапханәнең бәһа бирен бетергесез байлыгы. Алар арасында XII гасыр шәрекъ кулъязмаларыннан башлап, Второвлар тупланмасына, татар һәм рус классик язучылары, мәгърифәтчеләренең үзләре исән чагында нәшер ителгән китапларына кадәр бар.

**Национальная библиотека Республики Татарстан** – сокровищница культуры татарского народа. Это единственная публичная библиотека мира, занимающаяся вопросами комплектования, сохранения и распространения татарской книги и литературы о республике. Фонд библиотеки насчитывает более 3 млн. экземпляров произведений печати и других видов документов, в т.ч. 78 тыс. книг на татарском языке и свыше 80 тыс. изданий на западноевропейских и восточных языках. Здесь собрано около 14 тыс. экз. рукописной и редкой книги. Среди них восточные рукописи, начиная с XII в., коллекция Второвых, прижизненные издания классиков татарской и русской литературы и просветительства.

**The National library of the Republic of Tatartsan** is the treasury of Tatar culture. It is the only public library in the world dealing with the collection, storage and circulation of Tatar books and other editions that contain information about the republic. The funds of the library include over 3 000 000 copies of books and other editions and documents, among them over 78000 books in Tatar and over 80000 issues in western european and oriental languages. About 14 000 copies of rare books and manuscripts are available here. Among them there are ancient oriental manuscripts dated from the XII century, the Vtorovs' collection and contemporary editions of Tatar and Russian classic authors and educators.





# КЕШЕНЕ КЕШЕ ИТКӘН НӘРСӘ — КИТАПТЫР

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстан Республикасының Милли
китапханәсе директоры

Кешелекнең чын тарихы, цивилизацияле, аң-белемле тарихы Китап галиҗәнабләре дөньяга килгән чордан башлана. Язу уйлап табылганчыга, кулъязма һәм басма китаплар күренә башлаганчыга кадәрге заманны кешелекнең балачагы, хәтта тарихка да ныклап уелып калмаган чоры, дисәк, ялгыш булмас кебек.

Китап язган, китап бастырган, китап тараткан халыкның аң-белем дәрәҗәсе, уй-гамәл мөмкинлекләре язуы булмаган халыкларга караганда күпкә өстенрәк. Халыкны олы бер рух тирәсенә туплап, миллионлаган кешеләрне бер әхлак, бер гадәт-йола, бер тәртипкә күндереп килгән дин тәгълиматлары да безгә һәм безнең әби-бабаларыбызга, нигездә, "Олуг китап"— Коръән аша барып ирешкән. Димәк, безнең халыкны гасырлар буена Китап тәрбияләп, ышаныч һәм өмет биреп киләчәккә алып барган, тарих упкынына төшеп югалудан мөмкин булган кадәр саклап калган.

Китапның һәм китапханәләрнең дәүләт, җәмгыять һәм халык язмышында нинди зур урын тотканын борынгы заманнарда ук бик яхшы аңлаганнар һәм тәрәкъкыяткә ирешкән илләрдә моңа бүген дә бик яхшы төшенәләр. Императорлар һәм патшалар, ханнар һәм солтаннар үзләренең баш калаларында иң үзәктә китапханәләр өчен иң матур биналар төзеткәннәр.

Кайсы гына шәһәргә, кайсы гына илгә барсам да, иң беренче эшем итеп мин китапханәгә, базарга һәм зиратка кереп чыгам. Чөнки шушы өч урында булсаң, мондагы халыкның культура дәрәҗәсен, икътисади хәлен һәм үзенең үткәненә, тарихына мөнәсәбәтен күзаллый аласың. Әлләни ерак йөрмичә, үзебезнең Татарстан авылларына барсаң да, һәммә жирдә диярлек китапханә башка оешмалардан пөхтәлеге, чисталыгы, тәртибе белән аерылып тора. Татар авыларында әле хәзер дә китап укучылар китапханәгә, мәчеткә кергән кебек, аяк киемнәрен салып керәләр.

Татарстан Милли китапханәсенең төп бинасын белмәгән кеше бик сирәктер. 1919 елны, дөньяның асты өскә килгән заманда бу гүзәл бина безнең китапханәгә бирелә. Әле бүгенге көндә дә китапханә залларында бу йортның хуҗасы Ушковтан калган бәллүр люстралар эленеп тора, шул чорның шәмдәлләре, сәгатьләре, төрледән-төрле бизәкләре, серле мәгарәләре, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән каминнары — барысы да исән-сау, барысы да үз урынында.

Кайчакта уйланып куям: әгәр дә бу гаҗәеп бинаны берәр башка оешмага бирсәләр, дәүләт конторасы яисә кибет-мазар ясасалар, әлеге тарихи җәүһәрләр сакланган булыр идеме икән?

Илләр, дөньялар мең кат буталып, җәмгыятебез тәртипсезлекнең, әхлаксызлыкның соңгы чигенә җиткән бер чорда китапханәләрнең авырлык белән булса да җан асравы, аларда әле һаман да чисталык һәм пөхтәлек, халыкның рухи хәзинәләренә, тарихына олы хөрмәт, кешеләргә кешечә яхшы мөгамәлә саклануы — үзе бер куанычтыр. Чөнки безнең киләчәгебез кыргый эшкуарлар, надан малтабарлар, тар маңгайлы чиновниклар кулында булырга тиеш түгел. Алар килер дә китәр, халык калыр. Ә халыкның иң аңлы, иң өметле өлеше бүген, караңгы төнне учак янына ашыккан юлчы кебек, театрларга, музейларга, китапханәләргә килеп елыша, үз көнеленә алардан яктылык, җылылык алырга омтыла.

Китапханәгә бару, киштәләргә тезелеп сине көтеп торган акыл ияләре белән очрашып, күзгә-күз фикер алышу, андагы сихри тынлыкка чумып, хыял диңгезендә йөзү — һәркем өчен олы бер рухи бәйрәмдер.

# ЧЕЛОВЕК НАЧИНАЕТСЯ С КНИГИ

Разиль ВАЛЕЕВ,
директор Национальной библиотеки Республики Татарстан

Если вдуматься, то цивилизация, подлинная история человечества, да и сам человек, каким мы сегодня его знаем, начинается с появлением письменности, с рукописных и печатных книг. До этого развитие "существа разумного" находилось, можно сказать, в колыбельном возрасте, в периоде, как писал Лев Гумилев, "физиологического и предсознательного роста."

Народы, создавшие свою письменность, издававшие и распространявшие свои книги, были по духу и духовности, по культуре и просвещенности на голову выше существовавших вне письменности народов. На протяжении многих веков наш народ воспитывался и жил по канонам и заповедям своей главной духовной книги – Корана. Стало быть, остовом, внутренней опорой, которые не дали нашим дедам и прапрадедам в самые тяжелые, кровавые годы сломиться, помогли выстоять, выиграть, была Книга.

В какую бы страну, в какой бы город я ни приезжал, в первую очередь посещаю библиотеку, базар и кладбище. Они дают безошибочное представление об отношении данного народа к своей культуре, об его экономическом благосостоянии, об отношении к своему прошлому, своей истории. В татарских деревнях и сегодня библиотеки отличаются чистотой, опрятностью, какой-то особой ухоженностью. Там и поныне, входя в библиотеку, как в мечети, снимают обувь. Может, это оттого, что библиотеки раньше были при мечетях... Так или иначе, к книге и ко всему, что связано с нею, отношение у нашего народа возвышенное, трепетное.

В наше непростое время, когда рушатся империи, когда народы воюют с народами, когда с ног на голову встает мораль и, казалось бы, уж нет на свете ничего постоянного, надежного и обращенного лицом к простым людям, все также гостеприимно открываются двери библиотек. И в храмовой тиши люди соприкасаются с историей, художественной литературой, поэзией, и души их получают равновесие и уверенность. Сойдет пена, схлынет все наносное и фальшивое, останутся настоящие ценности, останется народ.





# MODERN MAN BEGINS WITH A BOOK

Razil VALEEV,
director
of the National Library
of the Republic of Tatarstan

The history of human civilization, modern humankind and man as we know him today, essentially began with the appearance of written language, manuscripts and printed books. All previous stages of human development refer to cradle age of **Homo Sapiens,** that is, to the period of "physiological and pre-conscious growth", in the words of Lev Gumilyov.

The spiritual, cultural and mental level of nations who created their own written language and literature, and who published and distributed their books, was significantly higher than that of all other nations located beyond the literary space.

For many ages our people were educated and lived according to the precepts and canons of their main spiritual book, the Koran. Thus, books formed a crucial base and an internal pivot that protected our forefathers from breakdown in the hardest, bloody years and helped them to overcome adversity.

Whenever I come to a foreign country or town, first of all I visit the local library, market and cemetery. They give the most exact information about the local economic conditions, the attitude of people to their culture, the attitude to their Past and their history. In Tatar villages even today the libraries are clean and well-kept, run with special care. Coming to the library, as to a mosque, the rural people take off their shoes. Probably, this is because libraries were formerly affiliated with mosques. In any case, the attitude of our people to books and to everything that is connected with literature, is very respectful.

In our complicated times, when empires are being destroyed and nations are fighting each other, when morality is being turned upside down and ordinary people often fail to find something permanent and reliable in the surrounding world, the doors of libraries are still hospitably open. In its shrine of silence people get involved with history, belle lettres and poetry, thus finding mental poise and the confidence they need so much. The froth will come down one day, washing away everything that is false and extraneous. But real values will remain and the people will remain for ever.




*Һич тә күңлем ачылмаслык*
*эчем пошса,*
*Шул вакытта мин кулыма*
*китап алам...*

Габдулла ТУКАЙ

*Когда не станет сил в душе моей,*
*Тогда я в книгу устремляю взгляд...*

Габдулла ТУКАЙ

*When I have no strength*
*in heart and soul,*
*It is books that help me*
*to survive...*

Gabdulla TUKAI

Татарстан Милли китапханәсе, җәмәгать китапханәсе буларак, 1865 елның 10 (24) гыйнварында Казан шәһәрендә ачыла. Аның нигезен китап белгече һәм төбәкне өйрәнүче галим Иван Алексеевич Второв тупланмасы тәшкил итә, анда 903 исемдәге 1908 нөсхә китап һәм вакытлы матбугат басмасы була. Әлеге тупланманы китап белгеченең улы — язучы, археолог һәм этнограф Н. И. Второв шәһәргә 1844 елда бүләк итә.

Национальная библиотека Татарстана была открыта в г. Казани 10 (24) января 1865 года как городская публичная библиотека. Основу библиотеки составила коллекция местного библиофила и краеведа Ивана Алексеевича Второва, которая первоначально насчитывала 903 названия и 1908 томов книг и периодических изданий. В 1844 г. коллекция была подарена городу его сыном Н.И. Второвым (литератором, археологом и этнографом) с целью организации общественной библиотеки.

The National Library of Tatarstan was founded in Kazan on January 10, 1865 as a city public library. It was based on the collection of local bibliophile Ivan Alekseyevich Vtorov. This collection initially included 903 titles and 1908 volumes of books and regular editions. In 1844 N.I. Vtorov, author, archaeologist and ethnographer, presented his father's collection to the city with the purpose of founding a public library.








*И. А. Второв — китапханәгә нигез салучы*

*И.А.Второв – основатель библиотеки*

*I.A. Vtorov, the founder of the library*

Китапханәнең төп бинасы — Казан шәһәренең иң матур архитектура корылмаларыннан берсе. Бу сәнгать әсәре 1906 елда, Алексей Ушков үтенече буенча, аның сөекле хатыны Зинаида Ушковага бүләк сыйфатында, талантлы мигъмар Карл Мюфке тарафыннан тудырыла.

Бу әкияти гыйлем йортының затлы ишекләрен дулкынланмыйча ачып керү мөмкин түгел!

Главное здание библиотеки – красивейшее сооружение города, рожденное в 1906 году творческим гением архитектора Карла Мюфке и любовью заказчика Алексея Ушкова к своей жене Зинаиде Ушковой, для которой и было возведено это произведение искусства.

В этот сказочный дом мы приходим сегодня на свидание со своими любимыми поэтами и мыслителями, художниками, композиторами, учеными, с волнующими нас героями и образами.

The main building of the library is one of the most beautiful houses in the city. It was built in 1906 by the talented architect Karl Muefke on the order of Aleksey Ushkov. Ushkov, inspired by a great love for his wife Zinaida, devoted this piece of art to her.

Today we come to this magic house to meet poets and philosophers, artists and composers, scientists and heroes and become greatly moved by characters of our favourite books.





*Библиофил Иван Второв тупланмасыннан алынган китапларның бер өлеше*

*Книги из собрания библиофила Ивана Второва*

*Books from the collection of bibliophile Ivan Vtorov*

Китаплар Сарае бу!

Кешелекнең акыл дәръясы саклана торган илаһи урын.

Рәт-рәт тезелгән китаплар – дәверләр катламы кебек.

Бу мәгарәгә үзен кояшка тиңләгән җиһангирлар, солтанатлы шәхесләр язмышы да, үлмәс дастан-әкиятләр дә, меңнәрчә халыклар тарихы да, акыл ияләренең яшәү фәненә өйрәткән тәгълиматы да сыйган.

Син, кадерле кеше, шушы китапханәнең саллы ишеге каршында туктал да, арслан башлы җиз тоткага орынгач, балачак әкиятеннән калган тылсымлы сүзне пышылда:

Сим-Сим, ач ишекне!..

*Марсель ГАЛИЕВ,*
*татар язучысы*

Это храм книги!

Это хранилище человеческой мысли.

Стеллажи, целые книжные стены – как материализованные века человеческой жизни на земле.

Здесь застыли чувства и мысли поэтов и мудрецов многих веков, судьбы больших и маленьких людей, целых народов, притчи и сказки, поучительные истории и история всего человечества.

И ты, дорогой друг, подойдя к библиотеке и взявшись за дверную ручку с золоченой головой льва, замри на секунду и произнеси про себя:

– Сим-Сим, откройся !..

*Марсель ГАЛИЕВ,*
*татарский писатель*

It is the temple of the book!

It is the storage of human thought.

Book-shelves, or rather book-walls are like material ages of human life on earth.

They consolidate the feelings and thoughts of poets and sages of many centuries, the fates of great and simple people, the destiny of nations, fables and fairy tales, stories of various people and human history in general.

And you, dear friend, just come to the library and touch the door-handle with the golden lion head, just stop for a moment and whisper inwardly:

Open Sesame!

*Marsel GALIYEV,*
*Tatar writer*







*Әхмәтһади Максуди — Казан шәһәре җәмәгать китапханәсенең Мөселман бүлегеン оештыручы*

*Ахматхади Максуди – организатор Мусульманского отделения Казанской публичной библиотеки*

*Akhmatkhadi Maksudi, the organizer of the Moslem Department at Kazan Public Library*

Казан җәмәгатъ китапханәсенең Мөселман бүлеге 1906 елның гыйнварында ачыла. Аны оештыручыларның берсе шәһәр Думасы депутаты, галим һәм мәгърифәтче, шул елда чыга башлаган «Йолдыз» газетасының мөхәррире Әхмәтһади Максуди була.

Бүлек башта борадәран Кәримевләрнең Печән базарындагы йортына урнаша, соңрак «Болгар» номерларының өченче катына күчерелә.

Фондта 915 исемдәге 1277 нөсхә китап исәпләнә. Бүлекне ачу өчен Дума 590 сум акча бүлеп бирә.

Отделение Казанской публичной библиотеки для мусульман открылось в январе 1906 года. Одним из главных организаторов его был депутат Городской Думы, ученый и педагог, редактор в том же году вышедшей в свет газеты “Йолдыз” (“Звезда”) Ахматхади Максуди.

Филиальное отделение было размещено сначала в доме Каримовых на Сенной улице, затем переведено в номера “Булгар” на третьем этаже.

Первоначальный фонд отделения составлял 915 названий в 1277 томах. Дума на организацию филиала выделила 590 рублей.

The Moslem Department of Kazan Public Library was founded in 1906.

One of its main founders was Akhmat Maksoudi, a deputy of the City Duma (council), a scientist and teacher, the editor of the newspaper Yoldyz (The Star) that was established in the same year.

The affiliate department was initially located in the Karimov house on Sennaya street. Later it was transferred to the second floor of the hotel BULGAR.

The initial fund of the department included 915 titles in 1277 volumes. The Duma allocated 590 rubles to found the department.


КРАТКАЯ ИСТОРІЯ ГОРОДА КАЗАНИ.
ОПЫТЪ КАЗАНСКОЙ ИСТОРІИ древнихъ и среднихъ времянъ
КАЗАНЬ въ ея прошломъ и настоящемъ
КАЗАНЬ в девятнадцатом столетии
СТАТЬЯ IV.
Корона Царства Казанскаго.
КАЗАНСКІЙ КАЛЕНДАРЬ и справочная книга на 1873 г.
УКАЗАТЕЛЬ КАЗАНИ.
КАЗАНСКІЕ ТАТАРЫ.
(УѢЗДЪ КАЗАНСКІЙ).
№ 53.
УКАЗАТЕЛЬ ГОРОДА КАЗАНИ и достопримѣчательностей

Тормышта китаптан да тугърылыклырак юлдаш булуы мөмкин түгел. Ул — беркайчан да “сатмый” һәм хыянәт итми торган дус-иптәш. Ул — авыр минутларда ышанычлы ярдәмче дә, салулаптаеп киткән чакларда ышанычлы таяныч та, җан җылысы да. Ялгыз калганда исә — эчкерсез киңәшче дә.

*Әхәт МУШИНСКИЙ,*
*язучы*

Нет надежней и вернее книги. Она не изменит и не предаст. Она, как никто другой, поддержит в трудную минуту, подскажет и научит на жизненном распутьи, согреет душу при великой печали и грусти. Она не отвернется от вас даже тогда, когда от вас отвернутся все.

*Ахат МУШИНСКИЙ,*
*писатель*

There is nothing more relible and true than a book. It will never betray or deceive. Like nothing else in the world it gives support in hard times, prompts and teaches on the road in life. It will comfort the soul in great trouble and disaster. It will never leave you alone even when all men leave you.

*Akhat MUSHINSKI,*
*writer*




ИСТОРІЯ РУССКАГО ТЕАТРА
DRESDENER GALERIE
СИМПАТІЯ НРАВОУЧИТЕЛЬНАЯ ИСТОРІЯ
НИЗВЕРЖЕННЫЙ ЗЕЛУЛЪ, ОБРАЗЕЦЪ ЗЛОБЫ
КЛЕОРАНДА И ПРИНЦЕССЫ ЗЕФИЗЫ.
ЧАСТЬ ПЕРВАЯ.
Москва.
Въ вольной Типографіи А. Рѣшетникова.
1794.
DIE GERECHTIKAIT
ИСТОРІЯ РУССКОЙ АРМІИ И ФЛОТА
ОТТѢНКИ МОЕГО СЕРДЦА.
МОСКВА, 1802.
ÆGYPTEN

Хәзерге татарларның бабалары борынгы заманнарда ук язулы халыклар рәтендә булганнар. Идел Болгарстаны чорында ук аларның үз шагыйрьләре һәм галимнәре булган, мәктәп һәм мәдрәсәләре эшләгән, кульязма китаплар таралган. Казан ханлыгы чорында бу төбәктә бай китапханәләр, хаттатларның (китаплар күчереп язучыларнын) аерым остаханәләре эшләп торган. Татарлар, дөньяның төрки халыклары арасында беренче буларак, 1722 елда ук китап басу эшенә керешәләр. 1917 елга кадәр якынча 15 мең исемдәге татарча китап дөнья күрә; бу, Рәсәйдә яшәүче барлык төрки халыклар тарафыннан чыгарылган китаплар белән чагыштырганда да, уннарча тапкыр күбрәк.

*Әбрар КӘРИМУЛЛИН,*
*академик, филология фәннәре докторы*

Предки современных татар были древнеписьменным народом, который еще в период Волжской Булгарии имел своих поэтов и ученых, уже тогда там были мектебе и медресе, нашла распространение рукописная книга. В период Казанского ханства в крае работали целые цехи переписчиков, имелись богатые библиотеки рукописных книг. Татары были первыми среди всех тюркских народов мира, приступившими к наборному книгопечатанию в 1722 году. До 1917 года было выпущено около 15 тысяч названий книг, что в десятки раз больше, чем все книги, изданные всеми тюркскими народами России до 1917 года.

*Абрар КАРИМУЛЛИН,*
*академик, доктор филологических наук*

The ancestors of modern Tatars are known to have an ancient written language of their own. In the period of Volga Bulgaria they had their own poets and scientists, mektebes and medresses (secular and religious schools).Manuscript books were also available. Guilds of copyists worked in the Kazan Khanate, adding new books to rich libraries of manuscripts. Tatars were the first among all other Turkic peoples of the world to start book - printing in 1772. Up to 1917 they issued over 15 thousand titles of books. This is tens times more than the number of books issued in the same period by all other turkic peoples of Russia.

*Abrar KARIMULLIN,*
*Academician, doctor of philological sciences*






ای، توغان تل، ای ماتور تل، ئەتکەم-ئەنکەمنڭ تلی!
دونیادا کوب نەرسە بلدم، سین توغان تل آرقلی!
خلق موڭلاری
پچان بازاری
جان آزقلاری
دیوانی



*...һәм мин оҗмахны китапханәгә охшатып күз алдыма китердем*

Хорхе Луис БОРХЕС,
аргентина язучысы

*И представлял себе я рай, похожим на библиотеку*

Хорхе Луис БОРХЕС,
аргентинский писатель

*And I imagined that heaven would look like a library*

Jorge Luis BORGES,
Argentinian poet and writer

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондында татар, гарәп, фарсы, төрек, рус һәм башка телләрдәге 13 меңгә якын нөсхәдә китаплар, мең берәмлектән артык кулъязма һәм фотоматериаллар, революциягә кадәр чыккан татар газета-журналларының төпләмнәре тупланган. Тарихка һәм мәдәниятка караган фундаменталь тикшеренүләр, кыйммәтле белешмә әдәбият, миниатюр басмалар, бер генә нөсхәдә калган китаплар саклана. Татар әдәбиятының һәм мәгърифәтчелегенең мәшһүр эшлеклеләре Шиһабетдин Мәрҗанинең, Каюм Насыйриның, Габдулла Тукайның үзләре исән чакта басылган хезмәтләре, Кол Гали иҗат иткән “Кыйссаи Йосыф” әсәренең кулъязма күчермәләре, 1699 елда күчереп язылган Коръән, XIV йөзгә караган фәлсәфи-әхлакый әсәрләр җыентыгы һ.б. шушы бүлек фондында урын алганнар.

В фонде отдела редких и рукописных книг сосредоточено около 13 тыс. экземпляров книг на татарском, арабском, персидском, турецком, русском и других языках, более тысячи рукописей и фотоматериалов, подшивки дореволюционных татарских периодических изданий. Хранятся фундаментальные исследования по истории и культуре, ценная справочная литература, миниатюрные издания, книги оставшиеся в единственном экземпляре. Здесь представлены прижизненные издания трудов выдающихся деятелей татарской литературы и просветительства Шагабутдина Марджани, Каюма Насыри, Габдуллы Тукая, рукописное “Сказание о Юсуфе” начала XIX в., “Коран”, переписанный в 1699 г., сборник философско-этических сочинений XII в. и т.д.

The fund of rare books and manuscripts contains about 13 000 copies of books in Tatar, Arabian, Persian, Turkish, Russian and other languages, over 1000 manuscripts and photocopies and pre-revolutionary Tatar peridicals. Fundamental studies in history and culture, valuable reference books, miniatures, books in single copy are also stored here. Coeval editions of works by outstanding Tatar authors and educators are represented here, among them books by Shigabutdin Marjani, Kajum Nasyri, GabdullaTukai, the manuscript of The Legend of Yusuf dated from the early XIX century, the copy of Koran dated from the 1699, and the collections of XII century philosophic essays, etc.

Россия әдипләренең һәм галимнәренең, мәшһүр эшлеклеләренең әсәрләре шулай ук зур кыйммәткә ия. Китапханәдә М.Ломоносовның, Н.Карамзинның, А. Герценның, Д.Менделеевның, К.Тимирязевның, И.Павловның үзләре исән чакта басылган хезмәтләре саклана. Гомер әсәрләре: Н.Гнедич тәрҗемәсендәге "Илиада" һәм В.Жуковский тәрҗемәсендәге, күренекле рәссам Ф.Преллер иллюстрацияләре төшерелгән "Одиссея"— кабатланмас басмалар. А.С.Пушкинның 1833 елда чыккан бик кыйммәтле "Евгений Онегин" басмасы монда саклана. Бу — шигырь белән язылган романның беренче тулы басмасы. А.С.Пушкинның 1829 елда дөнья күргән "Шигырьләр"е дә, мәшһүр рәссам А.Бенуа рәсемнәре белән басылган "Пика дамасы" да библиографик сирәк китаплар булып саналалар.

Чит илләрнең фикер ияләре һәм җәмәгать эшлеклеләре Марк Цицеронның, Жан Жак Руссоның, Герберт Спенсерның, Вольтерның XVIII - XIX йозләрдә басылган әсәрләре китапханәбез киштәләрендә урын алганнар.

Огромную ценность представляют произведения выдающихся деятелей, ученых и писателей России. В библиотеке хранятся прижизненные издания М.Ломоносова, Н.Карамзина, А.Герцена, Д.Менделеева, К.Тимирязева, И.Павлова. Уникальны по качеству перевода и оформления произведения Гомера "Илиада" в переводе Н.Гнедича и "Одиссея" в переводе В. Жуковского с иллюстрациями знаменитого художника Ф.Преллера. Здесь хранится ценнейшее издание А.С. Пушкина "Евгений Онегин", вышедшее в 1833 году. Это первое полное издание романа в стихах. Библиографическая редкость и "Стихотворения" А.С. Пушкина, увидевшие свет при его жизни в 1829 году, "Пиковая дама" с иллюстрациями выдающегося художника А.Бенуа.

В библиотеке широко представлены произведения зарубежных мыслителей и общественных деятелей, изданные в XVIII – XIX веках, – Марка Цицерона, Жана Жака Руссо, Герберта Спенсера, Вольтера...

The works of outstanding Russian politicians, scientists and authors are of great value. In the library are available contemporary editions of M. Lermontov, N. Karamzin , A. Herzen, D. Mendeleyev, K.Timeryazev, I. Pavlov. Especially unique are Homer's Iliad and Odyssey, brilliantly translated into Russian by N. Gnedich and V. Zhukovskiy and illustrated by famous painter F.Preller. Here is stored the extremely valuable volume of A. S. Pushkin's Eugene Onegin issued in 1833. It is the first complete edition of the novel in verse. The contemporary edition of Poems by A.S. Pushkin dated 1829 and the Queen of Spades illustrated by an outstanding painter A. Benoit are also bibliographic rarities in the library's collections

Works of foreign philosophers and authors are widely represented in the library, among them books by Marcus Cicero, Jean-Jacque Rouseau, Herbert Spenser, Voltair...





Безнең халык икмәк һәм китапны чипчиста ашъяулыкларга төреп саклаган. Икмәк белән китапка кагылыр алдыннан кулларын сабын белән юган. Шуңа күрә, китапка хөрмәт миңа бабамнар каны аша күчкән.

Үзем язганнарга да мин, алар китап булып басылып чыккач, аеруча бер хөрмәт белән карыйм. Һәр сүзе, һәр җөмләсе таныш булса да, аларны яңабаштан укып чыгам. Үз эшемә читтән тәнкыйть күзе белән карап бәя бирергә тырышам. Чөнки китаплар, кем тарафыннан язылуына карамастан, милли хәзинәне тәшкил итәләр.

Китап язучы буларак, ул китапны пропагандалаучы һәм кадерләп саклаучы китапханәчеләргә ихтирамым һәм рәхмәтем зур.

*Туфан МИҢНУЛЛИН,*
*Татар ПЕН - үзәге*
*президенты*

Книгу и хлеб народ наш хранил, заворачивая бережливо в чистое, белое полотенце. Перед тем, как взять хлеб или книгу, наши отцы и деды тщательно мыли руки. Трепетное отношение к книге всосано у меня с молоком матери.

С особым чувством я смотрю на свои сочинения, которые вышли в свет в образе книг. Хоть и знаю там чуть ли не каждую фразу наизусть, заново перечитываю их. Стараюсь смотреть на свою работу сторонним, критическим взглядом. Ибо кем бы ни была написана книга, она входит в кладовую национальной культуры.

Как автор, я с большим почтением и уважением отношусь к библиотекарям — людям, хранящим и пропагандирующим книги.

*Туфан МИННУЛЛИН,*
*президент Татарского*
*ПЕН-центра*

Our people used to keep bread and books wrapped in clean white towels. Before taking a piece of bread or a book our fathers and grandfathers carefully washed their hands. I imbibed this respectful attitude to books with my mother's milk.

With a special feeling I look at my works published in the form of books. Though I remember almost every phrase by heart, I read them again and again. I try to look at my works critically, as a stranger. Any book, whoever may have written it, adds to the treasury of national culture.

As an author I treat the librarians with great respect. They store and propagate books.

*Tufan MINNULLIN,*
*President of Tatar PEN-Center*















Сихри матурлыкка ия булган "мәгарә" дә — уку залы. Биредә илаһи тынлык хөкемдар; шуңа да китап аерым бер тәм, ләззәт белән укыла.

---

Для читального зала предоставлен и уникальной красоты грот. Тихо здесь и спокойно, и книги читаются по-особенному.

---

The reading-hall is designed as a grotto. The silence and unique scenery of this beautiful hall make reading really something special.



Ниндидер яхшы китапны укып чыкканнан соң үз тормышларының яңа бер чорын ачкан кешеләр бик күп! Безне борчый, аптырата һәм бутый торган сорауларга үз вакытларында барлык акыл ияләре дә юлыкканнар; ул сорауларның берсе генә дә игътибардан читтә калмаган һәм аларның һәрберсенә акыл ияләре үзләре фикерләгән дәрәҗәдә — сүз белән дә, бөтен тормышяшәешләре белән дә — җавап биргәннәр.

*Генри ТОРО,*
*америка язучысы*

Кешелекнең мең еллар дәвамында дөньядагы барлык тәрәккыятьле илләрдән җыелган үтә дә зирәк вә тәкъдир ителергә хаклы вәкилләре биредә безгә эзләнүләренең нәтиҗәләрен һәм акыл җимешләрен иң яхшы үрнәктә тәкъдим итәләр.

*Ралф ЭМЕРСОН,*
*америка философы һәм язучысы*

Как много людей, которые по прочтении иной хорошей книги открывали новую эру своей жизни! Те самые вопросы, которые беспокоят, смущают и путают нас, эти вопросы являлись в свое время перед всеми мудрыми людьми; ни один из них не был пропущен, пройден мимо и на каждый из них мудрецы ответили по своему разумению – и словом и всей своей жизнью.

*Генри ТОРО,*
*американский писатель*

Общество мудрейших и досточтимейших людей, избранное из всех цивилизованных стран мира на протяжении тысяч лет, представило нам здесь в лучшем порядке результаты своего изучения и своей мудрости.

*Ралф ЭМЕРСОН,*
*американский философ и писатель*

There are so many people who, having read a good book, began a new era in their life! There are so many questions that embarace, mislead and trouble us, the same questions concern all wise people; none were missed or bypassed, and each was answered by the sages. They answered these questions as they understood them - by words and by their lives.

*Henri THOREAU,*
*US naturalist and writer*

Here the society of the most wise and respected people for thousands of years from all civilized countries of the world has presented us the best results of their studies and their wisdom.

*Ralph EMERSON*
*US essayist, philosopher and writer*









Тарихта шәригать канунныры белгече-фәкыйһ, "Әл-Җәмигъ" нең авторы Әхмәд Болгари (XI гасыр), "Тәварихы Болгария" не биреп калдырган Йагкуб бине Ногман (XII гасыр), Сәмаркандинең атаклы "Адаб" трактатына шәрехләмә ясаган Борһанетдин Ибраһим бине Йосыф әл-Болгари (XII-XIII гасырлар) кебек бик күп бөек шәхесләрнең исемнәре сакланып калган. Ниһаять, XIII гасыр башында, дөресрәге, 1212-1233 елларда Кол Галинең тиндәшсез "Кыйссаи Йосыф" әсәре дөнья күрә. Боларның барысы да Идел буе Болгарстанында, монгол яуларына кадәр үк, язма әдәбият, китапчылык традицияләренең чәчәк атуы турында сөйли.

*Миркасыйм ГОСМАНОВ,*
*академик,*
*тарих фәннәре докторы*

Сохранились имена и названия сочинений таких булгарских ученых, как законовед по шариату Ахмед Булгари (XI в., автор книг "Ат-Тарика", "Аль-фаваид"), историк Йагкуб ибн-Нугман (XII в. "Тарихи булгар"), комментатор трактатов "Адаб" и "Усуль" Бурхан аддин Ибрагим ибн-Йусуф аль-Булгари (XII–XIII вв.) и т.д. Началом XIII столетия, точнее 1212–1233 годами, датируется создание вполне светского по содержанию и высокохудожественного по качеству поэтического произведения "Кысса-и Йусуф" ("Сказание о Йусуфе") Кул Гали. Все это свидетельствует о том, что домонгольский период Волжско-Камской Булгарии был отмечен своеобразным расцветом книжной традиции.

*Миркасыйм УСМАНОВ,*
*академик, доктор*
*исторических наук*

We still remember the names and works of Bulgar scientists, such as the researcher of the Shari'a Akhmed Bulgari (XI century) ,the author of "At-Tarika" and "Al-Favaid"), the historian Yagkub ibn-Nugman (XII century, Tarikhi Bulgar) and Burkhan addin Ibragim ibn-Yusuf al-Bulgari (XII-XIII centuries), commentator of the treatises "Adab" and "Usul'" etc. The poem "Kyssa i Yusuf" (The Legend of Yusuf) by Kul Gali is dated approximately from the early XIII century, specifically, 1212 -1233. This work is distinguished by its rather secular content and perfect poetic form. This is evidence that the pre-mongol period of Volga-Kama Bulgaria is marked by the blossoming literary tradition.

*Mirkasyim GOSMANOV,*
*academician, doctor*
*of historical sciences*






Сәнгать бүлегендә Сезгә мәдәниятнең төрле мәсьәләләрен яктырткан әдәбият, граммтәлинкәләр һәм башка аудиовизуаль материаллар тәкъдим ителә. Китапханәдә, башка традицион бүлекләр белән беррәттән, патентлар бүлеге, матбугат бүлеге, чит ил әдәбияты бүлеге эшли. Монда Сез гыйлемнең төрле тармакларына караган документлар белән таныша аласыз.

В отделе искусств вас ждет литература по различным вопросам культуры, грампластинки и другие аудиовизуальные материалы. В библиотеке, кроме традиционных отделов, также работают патентный отдел, отделы периодики, иностранной литературы. Здесь вы можете ознакомиться с документами по различным отраслям знаний.

In the department of fine arts there are books on various issues of culture, records and other audio and video materials. In addition to traditional ones, the departments of patents, periodicals, foreign literature are avalable in the library. Here you may find documents on various fields of knowledge.









АКШ ның 8 китапханәсе, Канаданың, Төркиянең, Голландиянең, башка якын һәм ерак чит илләрнең китап саклагычлары Милли китапханәнең халыкара китап алмашуында абунәчеләр булып торалар. Татарстанның төп китапханәсе Россиядә һәм башка төбәкләрдә татарларга хезмәт күрсәтүче китапханәләрнең фондларын тулыландыруда катнаша. Шулай ук безнең китапханә фондларына да дөньяның төрле илләреннән китаплар килә.

Абонентами международного книгообмена Национальной библиотеки являются 8 библиотек США, книгохранилища Канады, Турции, Нидерландов и других стран дальнего и ближнего зарубежья. Главная библиотека Татарстана участвует в докомплектовании фондов библиотек России и других регионов, обслуживающих татарское население. В свою очередь в фонды нашей библиотеки поступают книги из многих стран мира.

Among the borrowers of the international book exchange of the National Library are 8 libraries in the USA, libraries in Canada, Turkey, Netherlands and other countries. The main library of Tatarstan participates in adding to the funds of libraries in Russia and in other regions where the Tatar population is available. Many countries of the world add their books to our funds, too.



*Бу дөньяда бары гамь*
*мәңгелек,*
*Галиҗәнаб сүз тик —*
*мәңгерәк.*

Анна АХМАТОВА

*Всего прочнее на земле*
*печаль,*
*И долговечней — царственное*
*слово.*

Анна АХМАТОВА

*Sorrow is the most enduring thing on*
*Earth*
*Except for the words of the czar that*
*last for*
*ever.*

Anna AKHMATOVA

Җөмһүриятебезнең баш китапханәсе 1991 елда Милли китапханә статусын алды. Бүген ул — Идел буе мәдәниятенең әһәмиятле үзәге.

Татарстан Милли китапханәсе халыкара танылу да алды. Ул китапханәләрнең халыкара ассоциациясенә тулы хокуклы әгъза булып керде, аның барлык конгрессларында һәм акцияләрендә катнаша. Татарстан Милли китапханәсенең халыкара мәдәният галәменә турыдан-туры чыгуы, киң җәелгән китап алмашу эшчәнлеге, нәтиҗәле шәхси аралашулар төрле тарихи тамырларга, төрле дини инануларга һәм мәдәниятләргә караган халыкларны үзара якынайту эшенә бәяләп бетермәслек зур өлеш кертә. Татарстан Милли китапханәсенең халыкара даирәләрдә мөстәкыйль эш йөртүе - суверен җөмһүриятебезнең аякка басуы һәм тәрәккый итүе өчен тагын бер этәргеч.

Статус Национальной главная библиотека республики приобретает в 1991 году. Сегодня — это подлинный центр культуры Поволжья.

Национальная библиотека Татарстана получила и международное признание. Она входит полноправным членом в Международную ассоциацию библиотек, принимает участие во всех ее конгрессах и акциях. Прямой выход Национальной библиотеки Татарстана в сферу международной культуры, широкий книгообмен, плодотворные личностные контакты вносят неоценимый вклад в дело сближения народов различных исторических корней, вероисповеданий, культур. Самостоятельная деятельность Национальной библиотеки Татарстана на международной арене — еще один штрих в динамике становления суверенной республики.

The main library of the republic was awarded the title of National Library in 1991. Today it is a real center of culture in the Volga Region.

The National Library of Tatarstan is recognized abroad. As a full member of International Libraries'Association, it participates in all relevant congresses and meetings. Direct access to international culture, book exchange and fruitful personal contacts contribute much to the task of making various nations closer to each other, regardless of their historical roots, religion and cultural traditions. The independent operation of the National Library in developing foreign relations is one more evidence of the dynamic growth of the souvereign republic of Tatarstan.



*Кешеләр китап укудан тукта-
салар, фикер йөртүдән дә
туктарлар иде.*

*Дени ДИДРО*

*Люди перестают мыслить,
когда перестают читать.*

*Дени ДИДРО*

*People stop thinking when they
stop reading.*

*Denis DIDEROT*











Китапханәнең эшчәнлеге күпкырлы. Анда әледән-әле фәнни-гамәли (шул исәптән халыкара күләмдә дә) конференцияләр, язучылар белән очрашулар уздырыла, камера оркестры һәм артистлар чыгыш ясый. Елның елына иң популяр китап конкурсына йомгак ясала. “Бер сәнгать әсәре күргәзмәсе” оештырыла, китапка багышланган әдәби кичәләр дә укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.



Сегодня деятельность библиотеки широка и многогранна. Здесь постоянно проходят научно-практические конференции, в том числе и международные, встречи с писателями, концерты камерной музыки. Библиотека подводит ежегодные итоги самой читаемой книги. Организуются здесь выставки одного художественного произведения, часто проходят вечера книги.

Library life here is much more active than it is in conventional library organizations.

Research and practical conferences, both local and international, meetings with authors and concerts of chamber music are regularly held here. Our library adds up the annual rating of the most populare books. We organize single book exhibitions and readers’ discussions.







Татарстан Милли китапханәсе бинасында Бөтендөнья язучылар оешмасының — Халыкара ПЕН-клубның Татарстан ПЕН-үзәге урнашкан.Фоторәсемдә — татар әдәбияты классигы Габдулла Тукайга багышланган "түгәрәк өстәл"дә катнашкан бер төркем Татарстан ПЕН-үзәге әгзалары: (уңнан сулга) утырганнар — Туфан Миңнуллин, Миркасыйм Госманов, Әмирхан Еники, Илдар Юзиев, Нурихан Фәттах, Рафаэль Мостафин; басканнар — Ркаил Зәйдулла, Әхәт Мушинский, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев.

В стенах Национальной библиотеки Татарстана работает Татарский ПЕН-центр – составная Всемирной писательской организации (Международный ПЕН-клуб). На снимке — участники “круглого стола” Татарского ПЕН-центра, посвященного классику татарской литературы Габдулле Тукаю: (справа налево) сидят — Туфан Минуллин, Миркасыйм Усманов, Амирхан Еники, Ильдар Юзеев, Нурихан Фаттах, Рафаэль Мустафин; стоят — Ркаиль Зайдулла, Ахат Мушинский, Равиль Файзуллин, Разиль Валеев.

The Tatar PEN-Center affiliated with the International PEN-CLUB (The World Authors' Organization) has its Head-quarters in the National Library of Tatarstan. This picture shows partici pants of a round-table conference of Tatar Pen-center devoted to the Tatar classic poet Gabdulla Tukai: (right to left) front — Tufan Minnullin, Mirkasyim Gosmanov, Amirkhan Eniki, Ildar Yuzeev, Nurikhan Fattakh, Rafael Mustafin; behind — Rkail Zaidulla, Akhat Mushinski, Ravil Faizullin, Razil Valeev.

Безнең бай китап саклау мирасханәсенә тартынмыйча узыгыз. Һәм белегез, анда күп гасырлар дәвамында кешелекнең хакыйкатьне һәм матурлыкны аңлау юлындагы иң яхшы һәм гыйбрәтле үрнәкләре тупланган. Шулай ук акыл иясләренең уртак моназарә мәҗлесендә үзегезне чакырылмаган кунак итеп тә тоя күрмәгез, җаныгыз теләгән җирдән урын алыгыз. Менә шул чагында, төрле халыкларның төрле чорларда иҗат иткән шагыйрьләре, галимнәре, артистлары, тарихчыларының гүзәлдән-гүзәл мираслары белән күзгә-күз очрашкач, мөмкинлекләрегезнең чикләрен тәгаен билгели алырсыз һәм сезнең алда моңарчы күрелмәгән биниһая киңлекләр ачылыр.

*Пьер КОРНЕЛЬ*



Приходите в наши обширные книгохранилища. Знайте, что там собралось в течение многих веков все самое лучшее, самое полезное, чего достигло человечество в познании истины и красоты. Не считайте себя незваными гостями на пиру мудрецов. Займите там уготованное вам место. И тогда, с глазу на глаз с прекрасными творениями поэтов, ученых, артистов, историков всех времен и народов, вы правильно оцените свои способности, и вашим взорам откроются новые, широкие, неведомые горизонты. Приходите в библиотеки, обиталища знания!

*Пьер КОРНЕЛЬ*



Come to our libraries. And know that there is the best and most useful that humanity has achieved in its efforts to perceive truth and beauty. Do not feel yourselves as uninvited guests at a feast of sages. Take your own personal seat there. Then, alone with the beautiful works of poets, scientists, artists, historians of all times and nations, you will adequately undestand, your abilities, and vast new unknown horizons will open up before your eyes. Come to the library, the home of knowledge!

*Pierre CORNAILLE*



